СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**09.09.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 128**

Зеленодольск муниципаль районы Советы 2008 елның 22 августындагы 366 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 февралендәге 25-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль закон, 2016 елның 23 маендагы 143-ФЗ номерлы «Гражданнарның аерым категорияләренә пенсия яшен арттыру өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2008 елның 22 августындагы 366 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә хакында» Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Зеленодольск муниципаль район Советының 2008 елның 14 ноябрендәге 400 номерлы, 2009 елның 22 апрелендәге 435 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 136 номерлы, 2012 елның 1 августындагы 175 номерлы, 2015 елның 27 мартындагы 512 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) (алга таба – Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешне кертергә:

9.2 пунктының беренче абзацында, 9 кисәктә “15 ел” сүзләрен “, тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен аның озынлыгы гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**